# КАРАР

**17ноябрь, 2021 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 17 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә җиткән 3 яки аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр һәм ялгыз аналар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Киндер Күл авылы зиратын киртәләү, смета документлары;
- Киндер Күл авылында урам юл челтәрен карап тоту(ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), проект-смета документлары;
- Киндер Күл авылында энергия саклаучы лампаларны, яктырткычларны сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелек;
- Киндер Күл авылы территориясен төзекләндерү;
- Киндер Күл авылы урамнарына асфальт салу, проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек үткәрү, экспертиза үткәрү;
- Насослар сатып алу һәм урнаштыру;
- Юлларга вак таш җәю, Энергетиклар, Новая урамы, Насыйбуллин урамы, Киндер Күл авылы буенча торбалар сатып алу һәм җәю; (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек;
- Киндер Күл авылында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, смета документлары?;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 374 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 198кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 198 кеше тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә җиткән 3 яки аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр һәм ялгыз аналар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Киндер Күл авылы зиратын киртәләү, смета документлары;
- Киндер Күл авылында урам юл челтәрен карап тоту(ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), проект-смета документлары;
- Киндер Күл авылында энергия саклаучы лампаларны, яктырткычларны сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелек;
- Киндер Күл авылы территориясен төзекләндерү;
- Киндер Күл авылы урамнарына асфальт салу, проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек үткәрү, экспертиза үткәрү;
- Насослар сатып алу һәм урнаштыру;
- Юлларга вак таш җәю, Энергетиклар, Новая урамы, Насыйбуллин урамы, Киндер Күл авылы буенча торбалар сатып алу һәм җәю; (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек;
- Киндер Күл авылында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, смета документлары?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

ОГРН 1021607752957
ИНН 1623001533

Манзарас
авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хәбибуллина